ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» августа 2023 ел № 224

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 19.12.2006 елның 80-ТРЗ номерлы кодексына таянып, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 21.07.2023 елның 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәреш кертергә, аны әлеге карарга кушымта итеп бирелгән редакциядә текст белән тулыландырырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга(http://www.agryz.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Латыйпов**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетынын
05.07.2023 елның 193 нчы
номерлы карарына
1 нче кушымта
(карар редакциясендә
14.08.2023 № 227)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына өстәмәләр**

| ТР КоАП маддәләре | Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге | Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турындагы эшләрне ведомство карамагындагы хокук бозулар буенча карарга вәкаләтле органнар |
|---|---|---|
| **2.21 нче маддә** Режим кысаларындагы (база әзерлеге дәрәҗәсендәге) чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече | Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча 1 нче, 2 нче суд участоклары җәмәгать судьялары (ТР КоАП 7.1 маддәсе) |